| СОВЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«08» июнь 2020 нче ел Кошман авылы №10

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советының 2018 елның 01 октябрендәге 15 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 февралендәге 27-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына бюджет мөнәсәбәтләрен камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 02 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымтада каралганча үзгәрешләр кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 79 статьясындагы 3 өлешенең, 84 статьясындагы 5 өлешенең 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга.
3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бастырырга. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кошман авылы җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Кошман выл җирлеге
Советының
08 июнь 2020 ел
10 номерлы карарына кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«- Җирлек территориясен бәйрәмчә бизәү;

- җирлек территориясен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруда гражданнарның һәм оешмаларның катнашу тәртибен гамәлгә ашыру;

- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру.»

2. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 5 статьясының 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20,21,22 пунктлар өстәргә:

«20) үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яисә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү;

21) күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фондын төзү ысуллары, капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлау тәртибе турында мәгълүмат бирү;

22) күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарып булмый торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү очракларының тәртибен һәм исемлеген раслау.».

3.6 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктында «күзәтүчесез хайваннарны аулау һәм асрау чараларын» сүзләрен «тереклек итүче хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген» сүзләренә алмаштырырга.

4. «Гражданнарҗыены» 22 статьясында:

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены, анда торак пунктта яисә җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булганнарының яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булганнарының яртысыннан артыгының берьюлы бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән Җирлек Уставы нигезендә

гражданнар җыены Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта этаплап уздырыла. Шулу квакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.»;

3 өлешнең 2,3,4,6,7 пунктларын төшереп к алдырырга;

3 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирлек составына керә торган торак пунктта;».

5. 29 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланган 7 депутаттан тора».

5. 30 статьяның 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Җирлек Советы депутаты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү дә катнашуга:

а) сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәр итеп, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай УК аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру

тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагыөлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3)укытучылык, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул УК вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик читдәүләтләр, халыкараһәмчит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.».

7. 30 статьяның 10 өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә.

8. 30 статьяның 12 өлешенә «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «яисә күрсәтелгән затларга карата җаваплылыкның башка чараларын» сүзләрен өстәргә.

9. 30 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12.1, 12.2 өлешләр өстәргә:

«12.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында ялган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи затына, җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр әлеге белешмәләрне бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

кисәтү;

Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын Җирлек Советындагы вазыйфадан, җирле үзидарәнең сайланулы органыннан үз вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, Җирлек Советында вазыйфасын биләү хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан азат итү;

Җирлек Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

12.2. Җирлек советы депутатына, Җирлек башлыгына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

10. 33 статьяның 1 өлешендәге 24 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

11. 43 статьяның 5 өлешенә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

12. 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Җирлек Башлыгы түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашуга:

а) сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәр итеп, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3)укытучылык, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлекәгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарынд абашкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.».

13. 45 статьяның 8 өлешенә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән башкасы каралмаган булса, » сүзләрен өстәргә.

14. 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Җирлек Башлыгы урынбасары түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашуга:

а) сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәр итеп, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль Җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтүгә;

г) муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3)укытучылык, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлекәгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары

тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.».

15. «Җирлек Башкарма комитетының вәкаләтләре» 49 статьясында:

1 өлешнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«-«ирекле төзелешне җимерү турында, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турындагы карарны Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә кабул итә;

-күп фатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә капиталь ремонт фондын төзү ысуллары, капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлау тәртибе турында хәбәритә;

- күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә өстәмә ярдәм күрсәтү өчен бюджет чаралары исәбеннән кире кайтарып алу һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә бюджет чаралары исәбеннән күрсәтү очракларының тәртибен һәм исемлеген раслый.».

1 өлешнең 4 пунктындагы 2 абзацында «кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыра» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 өлешнең унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;»;

3 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге Җирлек Советы билгеләгән тәртиптә алып барыла;»;

3 өлешнең 4 пунктында «җирлектә вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра торган муниципаль контрольдән тыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

16. 59 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен әлеге Устав нигезендә Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган чорга эш урынын (вазыйфаларын) саклау гарантияләнә һәм, тулаем алганда, аена ике һәм алты эш көненнән дә ким булмаска тиеш.».

17. 82 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль эчке алынмалар дигәндә муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыру юлы белән һәм Россия

Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә җирле бюджетка заем акчаларын җәлеп итү күздә тотыла».

18. «Муниципаль финанс контроле» 85 статьясында:

1 өлешнең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен, физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

2,3 өлешләрдә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.